# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге составына керүче Юеш Көрнәле авылы торак пунктында

18 декабрь 2021 е. № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге составына керүче Юеш Көрнәле авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда Бутлеровка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган 1 төркем инвалидлардан, уку студентларыннан, гражданнардан тыш, гражданнарның үзара салымын 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:
   - җирлек эчендәге юлларны ремонтлау, төзекләндерү һәм карап тоту;
   - урамнарны яктырту;
   - спорт мәйданчыгын төзекләндерү;
   - сугышта һәлак булганнарга һәйкәлне төзекләндерү;
   - парк зонасын төзекләндерү.
3. Әлеге карарны Бутлеровка авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы И.Л. Хушанова